Чыганак: Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская: әдәби нәфис, документаль, биографик җыентык / авт.-төз. Җ. Миңнуллин (фәнни мөх.); редкол.: И. Г. Әхмәтҗанов, Р. И. Вәлиев, Ф. М. Рәфыйков. – Казань: Җыен, 2012. – 479 б.: фоторәс. б-н. – (Шәхесләребез). – Библиогр.: б.465-474.

***Асия Галиева***[1]

# Күңелне нурландыра

Актёр тормышында актёрлык язмышы очраштырган тарихи шәхесләр дә була. Мин дә сәхнәдә беренче татар актрисасы образын иҗат итәргә туры килер дип башыма да китермәгән идем. Нәкый ага Исәнбәтнең «Гөлҗамал» пьесасы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куеласы булгач, миңа нәкъ шул бурыч йөкләнде. Билгеле ки, Гөлҗамалның прототибы – Сәхибҗамал Гыйззәтуллина.

Аңлашыла ки, үз алдыма актрисаның төгәл портретын күрсәтүне максат итеп куймадым мин. Бу мөмкин дә булмас иде. Бурыч – беренче татар актрисаларына хас иң кыйммәтле сыйфатларны үзенә туплаган җыелма образ иҗат итү. Шулай да, Н.Исәнбәтнең бу талантлы пьесасы героинясында, нәкъ менә Волжскаяның үзен, аның сыйфатларын, аның характерын танымау мөмкин түгел иде. Бу – көчле кеше, күренекле актриса, театр эшлеклесе, «Нур» труппасын төзегән һәм татар театры артистларының зур төркемен тәрбияләгән актриса характеры.

Шулай килеп чыкты инде, мин элегрәк тә һәм спектакльне әзерләү чорында да Волжскаяның үзен күрә алмадым. Аны А.В. Луначарский исемендәге ГИТИСта уку елларымда гына ничектер бер күргән идем. Ул профессор О.И. Пыжова җитәкчелегендәге татар студиясенең актёрлык осталыгы дәресендә катнашкан иде. Кайчан да булса мин сәхнәдә аның образы белән күзгә-күз очрашырмын дип уйлый ала идеммени?! Шуңа күрә Гөлҗамал образын әзерләгәндә миңа пьесаның эчтәлеге, беренче татар артистлары хакындагы материалларны өйрәнү, аларның фоторәсемнәрен карау белән чикләнергә һәм хыя-

[1] *Асия Галиева (1929)* – Татарстанның халык артисткасы.

лымдагы образны гәүдәләндерергә туры килде. Ә аның үзен Казанда «Гөлҗамал» спектаклен тапшырган көнне күрдем. Ул беренче рәттә утыра иде. Соңыннан аны, спектакльдән соң хисләнеп, елап та алды, дип сөйләделәр. Без аның белән спектакльдән соң очраштык. Ул миңа театр, Г.Кариев һәм театрдагы иптәшләре, «Сәйяр», «Нур» труппалары, яраткан кешесе, аның хатлары һәм үзенең тормышы хакында озак сөйләде.

Бу күрешүдән соң безнең арада нык дуслык урнашты. Без аның белән язышып (ул Иж шәһәрендә яши иде), Казанга килгән саен очрашып тордык. Хәзер еш кына минем аның турында сөйләвемне үтенәләр, һәрвакыт бик теләп риза булам һәм зур дулкынлану белән сөйлим. Чөнки аның исеме, эше, гүзәллек хакына, сәнгать хакына театрга багышланган тормышы алдында баш иям.

Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская ябык кына, төз генә бер ханым иде. Ул һәрвакыт бик җыйнак, өендә дә матур итеп, пөхтә киенгән була иде. Йөрешендә, карашында, бөтен килеш-килбәтендә горурлык һәм бәйсезлек бөркелә. Шул ук вакытта ул бик табигый да. Гәүдәгә зур булмаса да, ул эре күренә. Йөреше, үз-үзен тотышы, тавышы аны зурайтыбрак күрсәтә, аның рухи бай дөньясын чагылдыра. Әңгәмәдәшен ул туры, кырыс карап, игътибар белән тыңлый. Әкрен сөйли һәм аның фикер сөреше бик төгәл була иде. Инде өлкән яшьтә булуына да карамастан, ул гаҗәп яшь күренә һәм бик әйбәт күкрәк тавышы белән сөйләшә. Аның сөйләме чип-чиста әдәби телдә булып, төрки телнең күп мәгънәле сүзләренә бай иде. Мине аның зирәк акылы һәм фикеренең төгәл, эзлекле агышы таң калдыра иде. Шулай ук аңарда артык хисләнүчәнлек тә күрмәдем. Беренче очрашудан ук мин аның көчле, ихтыярлы характерын сиземләдем. Кайчакта ул миңа артык кырыс та булып тоела иде. Әмма

очрашудан-очрашуга мин аның шәфкатьле һәм йомшак кеше булуына төшенә бардым. Ул сирәк елмая иде. «Гөлҗамал» спектакленең премьерасыннан соң төшерелгән фоторәсемендәгедән шатлыклырак елмаюын тәгаен хәтерли алмыйм.

Кайчагында миннән Волжскаяның нindирәк пландагы актриса булуын сорашалар. Миңа аның сәхнә уенын күрү насыйп булмады. Очрашканда аны сәхнәдә итеп күрергә тырышып, игътибар белән күзәтә идем. Әлбәттә, күпмедер дәрәҗәдә аның иҗат амплуасын һәм кайбер актёрлык мөмкинлекләрен чамаларга була. Тышкы кыяфәтен, тавышын, үзүзен тотышын анализлап, мин аны актриса буларак танып белергә тырыштым. Миңа ул героик-романтик пландагы актриса булгандыр кебек тоела. Шуның белән бергә, ул бик реалистик та. Һәрхәлдә, ул көнкүреш актрисасы түгел иде. Аңардан героика, күтәренкелек бөркелә иде. Ләкин ул гаять тормышчан кеше, тормышка реалист буларак карый. Некрасовның реалистик шигырьләрен укуын хәтерлим. Иҗатының реалистик җирлектә булуы – шуннан. Бәлкем, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская иҗаты кайсыдыр яклары белән татар Ермоловасы[1] итеп кабул ителүгә бик хаклыдыр. Сүз уңаеннан әйтим, аңа рус театрының йогынтысы зур булган.

Сәхибҗамал апа Волжская белемле, интеллигент кеше иде. Ул әдәбиятны, сәнгатьне, культураны яхшы белә. Очрашу саен мин аның олы һәм изге бер хис – үзен театр вәкиле итеп тою хисе белән горурлануын күрә идем. Аңарда театрга мәхәббәт зур иде. Ул, игелекле эш кешесе буларак, һәрвакыт иҗат интереслары мохитендә генә яшәде.

С.Гыйззәтуллина-Волжская халыкта бик лаеклы рәвештә популярлык казанган. Һәм, һичшик-

---

[1] *...татар Ермоловасы...* – Мария Николаевна Ермолова (1853–1928) – рус актрисасы. Республиканың халык артисткасы, Хезмәт батыры.

сез, аның тынгысыз, авыр һәм максатчан тормышы, иҗаты белән кызыксыну, аны өйрәнү дә зур шатлык китерер. Тукайча әйтсәк, «күңелне нурландырыр».

Без, хәзерге буын артистлары да, аның шул иҗат нуры йогынтысын сизәбез. Без аңа шуның өчен рәхмәтле.

*(«Социалистик Татарстан». – 1976, 9 декабрь. Текст газетадан алынды.)*

***Халит Кумысников***[1]

## Сәхнә йолдызы

Татар хатын-кызларыннан беренче кеше буларак сәхнәгә аяк басканда, Сәхибҗамал төрле милләтчеләр һәм дин әһелләре тарафыннан каршылык очратачагын, аларның мәсхәрә итәргә тырышачакларын, бәддога укыячакларын яхшы аңлый. Башкача булуы мөмкин дә түгел, чөнки ул гасырлар буена хатын-кызны кол хәлендә яшәргә мәҗбүр иткән ислам дине кануннарына каршы күтәрелә. Әмма шулай да япь-яшь кызның артистка булу, сәхнәдә хатын-кыз образларын гәүдәләндерү теләге һәммә нәрсәдән өстен булып чыга.

Столыпин реакциясе елларында артисткага бигрәк тә кыенга килә: карагруһчылар башта аны юмалап, байлыкка, рәхәт тормышка кызыктырып карыйлар, аннары яныйлар, куркыталар, ә инде алай да барып чыкмагач – үтереп ташларга ук ниятлиләр. Әмма туташны үзе сайлап алган кыйбласы – халыкны агарту өлкәсендәге фидакарь хезмәт юлыннан берни дә тайчандыра алмый.

---

[1] *Халит Лотфулла улы Кумысников* (1926–2008) – театр белгече.